**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13Совет урамы, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**3 февраль 2025 ел** **№ 119**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28, 44 статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 декабрендәге 152 номерлы (Советның 2020 елның 11 августындагы 172 нче номерлы, 2021 елның 15 гыйнварендагы 15 нче номерлы, 2022 нче елның 19 нчы августындагы 51 нче номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 84 нче номерлы карарлары редакциясендә) карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын федераль һәм региональ законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проектын нигез итеп кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл

җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча килүче тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитеты (алга таба - Оештыру комитеты) төзергә:

1) Никитенко Р.Р. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башлыгы урынбасары, оештыру комитеты рәисе;

2) Зиятдинов К.М. – Красносельский авыл җирлеге Советы депутаты, оештыру комитеты рәисе урынбасары;

3) Зиганшина Г.А. – Красносельский авыл җирлеге Советы депутаты, оештыру комитеты әгъзасы.

4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы карары проекты буенча 2025 елның 25 февралендә 9.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13 нче йорт адресы буенча гавами тыңлауларны билгеләргә.

5. Гавами тыңлаулар уздыру буенча Оештыру комитетына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне, исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмати стендында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре бүлегендә», һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов

1 нче кушымта
Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2025 елның 3 февралендәге 119 нче номерлы карары белән расланды

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

422700, Татарстан Республикасы, Биектау райо
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы,13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**_________________ 2025 ел** **№ ____**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 декабрендәге 152 номерлы (Советның 2020 елның 11 августындагы 172 нче номерлы, 2021 елның 15 гыйнварендагы 15 нче номерлы, 2022 елның 19 августындагы 51 нче номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 84 нче номерлы карарлары редакциясендә) карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 пунктында «, кыскартылган исеме - «Красносельский авыл җирлеге» сүзләрен өстәргә;

2) 6 статьяның 1 пунктында:

а) 12 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы

мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, авыл җирлегендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

б) Түбәндәге эчтәлекле 21 пунктча өстәргә:

«21) 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру. »;

3) 20 статьяның 5 пунктындагы 2 абзацында «1-7 пунктлар белән» сүзләрен «1-7 һәм 9.2 пунктлар белән» сүзләренә алмаштырырга.;

4) 32 статьяның 14 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

5) 35 статьяның 1 пунктындагы 26 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26 муниципаль хокукый актларны, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

6) 35 статьяның 1 пунктындагы 33, 39 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

7) 42 статьяда:

а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:

«13) затның чит ил агенты статусын алуы;»;

б) 13нче пунктчаны 14нче пунктча дип санарга;

8) 48 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 18 пунктча өстәргә:

«18) затның чит ил агенты статусын алуы.»;

9) 51 статьяның 8 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча эшли, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, авыл җирлегендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

10) 63 статьяның 3 пунктында «Җирлек сайлау комиссиясенең,» сүзләрен төшереп калдырырга;

11) 64 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләргә аңа билгеле булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә), яллаучы вәкиле карары белән үзгәртелгән белешмәләрдән ты, язма рәвештә хәбәр итәргә (алга таба-анкетадагы белешмәләр).»;

13) 86 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«86 статья «Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе»

1.Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар,Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельское авыл җирлеге гамәлгә куйган

оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актларшулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып санала:

1)Тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; 2013 елның 17 декаберендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәте (Роскомнадзор) ЭЛ ФС77-60244 номерлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) яки «Биектау хәбәрләре» газетасында (2011 елның 7 декабрендә ЭЛ ФС 77 – 47612 номерлы элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән).

2) Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Авыл җирлекләре бүлегендә» һәм Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмати стендында урнаштыру.

3. Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында, гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган матбугат басмаларының, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, челтәр басмаларының исемлеге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән бөтен кешегә җиткерелә ».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен

җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 нче статьясындагы 8 нче өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Никитенко Р.Р. йөкләргә.

Совет Рәисе,
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов

2 нче кушымта
Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2025 елның 3 февралендәге 119 нче номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу ТӘРТИБЕ һәм Фикер алышуда гражданнарның катнашу ТӘРТИБЕ**

1. 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясындагы 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында проектка тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашуы тәртибе (алга таба - Тәртип) проект буенча фикер алышуда катнашу хокукын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында гражданнарның тәкъдимнәрен кертү тәртибен беркетә.

2. Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге халкы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проектны игълан иткән вакыттан алып аның турында фикер алышуда түбәндәге формаларда катнашырга хокуклы:

1) яшәү урыны буенча гражданнар җыелышларын үткәрү;

2) әлеге Тәртип нигезендә Устав проектын массакүләм фикер алышу;

3) Устав проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү;

4) гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка формаларда.

3. Тәкъдимнәр Красносельский авыл җирлегенә түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13 йорт, телефон 8(84365) 2-35-82.

4. Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр, җитәкченең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, яшәү урынын (гражданнар өчен), юридик адресын, җитәкченең мөһере белән имзасын һәм таныкланган имзасын күрсәтеп, - юридик затлар, иҗтимагый оешмалар, берләшмәләр өчен имзаланырга тиеш.

5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (алга таба – тәкъдимнәр) халык тарафыннан гавами тыңлауларда тәкъдим ителгән өстәмәләр һәм (яисә) үзгәрешләр турындагы тәкъдимнәр гавами тыңлауларның йомгаклау документында күрсәтелә, ул Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу буенча оештыру комитетына (алга таба - эш төркеме) тапшырыла.

6. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) проектка халыкның тәкъдимнәре эш төркеменә басылып чыккан көннән алып 20 көн дәвамында кертелә һәм әлеге Тәртип нигезендә аның тарафыннан карала.

7. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәр актив сайлау хокукына ия Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан кертелергә мөмкин.

8. Граждан (гражданнар төркеме) устав проекты буенча, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә, тәкъдимнәрне рәсмиләштерә һәм аларны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу буенча эш төркеменә җибәрә.

9. Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы депутатлары Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы Регламентында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәр кертәләр.

10. Кертелгән тәкъдимнәр эшче төркем тарафыннан теркәлә.

11. Тәкъдимнәр Россия Федерациясе Конституциясенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына туры килергә тиеш.

12. Тәкъдимнәр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1) устав проекты нигезләмәләренең бер мәгънәле аңлатмасын тәэмин итәргә тиеш;

2) устав проектының башка нигезләмәләре белән каршылыкка йә килешмәүгә юл куймаска.

13. Әлеге тәртиптә каралган таләпләрне һәм срокларны бозып кертелгән тәкъдимнәр караусыз калдырылырга мөмкин.

14. Кертелгән тәкъдимнәрне өйрәнү, анализлау һәм гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча эшче төркем бәяләмә төзи.

15. Кертелгән тәкъдимнәргә эш төркеме бәяләмәсендә түбәндәге нигезләмәләр булырга тиеш:

1) кергән тәкъдимнәрнең гомуми саны;

2) әлеге Тәртип нигезендә каралмыйча калган тәкъдимнәр саны;

3) әлеге Тәртип тарафыннан куелган таләпләргә туры килмәү сәбәпле кире кагылган тәкъдимнәр;

4) эш төркеме тарафыннан кире кагылуга тәкъдим ителгән тәкъдимнәрне;

5) Устав проекты текстына кертү өчен эш төркеме тарафыннан тәкъдим ителә торган тәкъдимнәр.

16. Эш төркеме Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советына үз бәяләмәсен һәм эш төркеме эшчәнлеге материалларын кергән

барлык тәкъдимнәрне дә кертеп тәкъдим итә.

17. Кабул итү турындагы (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында проект текстына кертү) яисә тәкъдимнәрне кире кагу турындагы мәсьәләне хәл итү алдыннан Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы эш төркеме җитәкчесенең яки эшче төркем вәкаләтле әгъзасының эш төркеме эшчәнлеге турында докладын тыңлый.

18. Кабул ителгән тәкъдимнәрне мәҗбүри үз эченә алган устав проекты буенча гражданнардан кергән тәкъдимнәрне карау йомгаклары халыкка игълан ителергә тиеш.

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында фикер алышуда
гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибенә
карата

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында, аның турында фикер алышканда гражданнар тарафыннан кертелә торган закон проекты буенча тәкъдим**

| № | Пункт, пунктча, статья | Устав проекты тексты | Төзәтмәләр тексты | Устав проекты тексты төзәтмәне исәпкә алып | Төзәтмә кем тарафыннан кертелгән |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында проект буенча тәкъдимнәр керткән граждан (гражданнар төркеме) турында мәгълүмат**

| | |
|---|---|
| Тәкъдим керткән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (гражданнар) | |
| Өй адресы, телефон | |
| Шәхесне раслаучы документ турында мәгълүматлар | |
| Эш, уку урыны | |

Граждан имзасы (гражданнар) Дата